Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№ 28 03.10.2016 ел

Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы, Сөнчәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 7 а номерлы карары, Сөнчәле авыл җирлеге Советының «референдум үткәрү инициативасы турында»2016 елның 23 сентябрендәге 26 номерлы карары нигезендә

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советы КАРАРы:

1. Сөнчәле авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 20 ноябрендә якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1. 2017 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән; 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә: алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы: Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру.

- Сөнчәле авылы өчен насос сатып алу
- Кече Сөнчәле авылы өчен насос сатып алу
- Толстой урамындагы коены төзеклəндерү

- 2.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

- Сөнчәле авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә кышкы чорда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту
- Сөнчәле торак пункты эчендә юлларны вак таш белән каплау һәм тигезләү

2. Сөнчәле авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү

- Сөнчәле авыл җирлеге торак пунктларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру

ӘЙЕ ЮК

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум даирәсен билгеләргә.
4.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Сөнчәле авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.
5.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.
6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- ТР, Аксубай районы, Сөнчәле авылы, Ленин урамы, 80 нче йорт;
- ТР, Аксубай районы, Кече Сөнчәле авылы, Гагарин ур., 38

Сөнчәле авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.В.Крайнова

СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ